
# Мәктәп хәбәрчесе

**№8**
**(№21)**
**декабрь**
**2020 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


## “Мәктәп хәбәрчесе” үзебездә бастырыла башлады !



Билгеле булганча, гәзитебезнең алдагы номерлары барысы да район үзәгендәге “Квант” фирмасында бастырылып килде. Чөнки мәктәптә А-3 форматында бастыра торган принтер юк иде. Инде менә ниһаять, үзебезнең кече басмаханәбезне булдыруга ирештек! Моңа декабрь башында район үзәгендә үткәрелгән Туган телләргә багышланган төбәк семинарында катнашуыбыз сәбәп булды.

2021-нче ел Татарстан Республикасында Туган телләрне саклау һәм халыклар бердәмлеге елы буларак билгеләп үтеләчәк. Бу юнәлешне президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миннеханов бүгенге көндәге вәзгыятьтән, ягъни милли телләргә игътибарны арттыру зарурлыгыннан чыгып сайлады. Шул уңайдан 3-нче декабрь көнне Аксубай район үзәгендә Татарстанның Кама аръягы төбәгендәге 9 район вәкилләре катнашында республика семинары уздырылды. Безнең мәктәп тә бу чараны әзерләү һәм үткәрүгә зур өлеш кертте. Район мәдәният йортында урнаштырылган күргәзмәдә мәктәбебез директоры Рафик Насыйров нәсел шәҗәрәләренә багышланган шәхси экспозициясен күрсәтте. Ә Аксубайның 3-нче мәктәбендәге күргәзмәдә безнең “Мәктәп хәбәрчесе” гәзитенең стенды урнаштырылды.

Күргәзмә белән танышканда Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов һәм башка дәрәҗәле кунаклар безнең “Мәктәп хәбәрчесе” гәзите проекты буенча чыгышыбызны аеруча игътибар белән тыңладылар. Төрле сораулар бирделәр, мәктәбебез тормышы белән кызыксындылар. Сөйләшүләр барышында, үзебезнең мәктәп укучысы, бүгенге көндә “Шәһри Казан” гәзитенең баш мөхәррире булып эшләүче Радик Сабиров, “Мәктәп хәбәрчесен” бастыру өчен техник чараларга мохтаҗ икәнлегебезне белдерде. Марат әфәнде шунда ук бу тәкъдимне хуплап, безнең мәктәпкә киңформатлы принтер бүләк итәргә күрсәтмә бирде. Бу эшне «Татагролизинг» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Азат Илдус улы Җиһаншин** үз өстенә алды. Шуннан соң, атна-ун көн эчендә көтеп алган принтер мәктәпкә тапшырылды. Алла теләсә, “Мәктәп хәбәрчесенең” алдагы саннары үзебезнең кече типографиябездә бастырылачак. Шушындый олы бүләге өчен мәктәп коллективы исеменнән Азат әфәндегә олы рәхмәтләребезне белдереп, җаваплы эшендә уңышлар, үзенә һәм гаиләсенә саулык-иминлекләр телибез.

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина***

## Яңа ел котлы булсын!




Кыш Бабайның капчыгында,
Тәм-томнар арасында,
Килсен иде сәламәтлек,
Һәрберебезгә бүләрлек.

Өләшсен иде тырышлык
Һәр эшкә өлгерерлек.
Бирсен иде үҗәтлек
Максатларга җитәрлек.



*Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы*
*Түбән Майна урта мәктәбенең*

**РӘХМӘТ ХАТЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты,
“Татагролизинг” акционерлык җәмгыяте Генераль директоры
**Җиһаншин Азат Илдус улына**

Хөрмәтле Азат әфәнде!

Сезнең ярдәмегез белән мәктәбебездә нәшер ителә торган “Мәктәп хәбәрчесе” газетасы өчен киңформатлы төсле бастыру җайланмасы алынды. Әлеге олы бүләгегез белән яшь буынны укыту һәм тәрбияләү эшенә зур өлеш кертәсез. Түбән Майна мәктәбенә карата күрсәткән кайгыртучанлыгыгыз өчен барлык укучылар, әти-әниләр һәм хезмәткәрләрнең ихлас рәхмәтләрен белдерәм.

Алдагы елларда да туган җиребез һәм халкыбызның якты киләчәге өчен бергәләшеп гамәл кылуда булсак иде.

*Түбән Майна урта мәктәбе директоры* *Р.Г.Насыйров*

Түбән Майна – 2020

## *Чирек нәтиҗәләре*

***/Рәсми хәбәрләр/***

Уку елының беренче яртыеллыгы да тәмамланды. 25-нче декабрьдә 53 укучыбызның 49-ына чирек билгеләре чыгарылды. Мәктәп буенча белем сыйфаты 57,2% тәшкил итте. III сыйныфтан Закирова Ләйсән, IV сыйныфтан Гафиятуллин Фаил чирекне бары тик 5-ле, ә 26 укучы 4-ле һәм 5-ле билгеләренә тәмамладылар.

Бу чирек кыска булса да, уку буенча җаваплылык бермә-бер арта торган вакыт. Район олимпиадаларында катнашып, мәктәбең өчен дә, үзең өчен дә җаваплылык тоясың. Быелгы уку елында фән олимпиадаларының район турында X сыйныфлар арасында рус әдәбиятыннан **Насыйрова Сара** (укытучысы **Нәҗметдинов Раушания Рөстәм кызы**), биологиядән **Мөхәммәтова Рузилә** 1-нче урыннарны алдылар (укытучысы **Гафиятуллина Руфия Әмир кызы**). IX сыйныфлар арасыннан рус теленнән һәм татар теленнән **Туктамышева Әминә**, рус әдәбиятыннан һәм татар әдәбиятыннан **Нукина Вика**, IV сыйныфлар арасында татар теленнән **Залиева Вәсилә** призерлар булдылар (укытучылары **Кадыйрова Гөлнур Габделхак кызы**, **Гафиятуллина Фәнүзә Госман кызы** һәм **Хәйруллина Рузилә Әдһәм кызы**). Мәктәп данын яклаган укучыларга киләчәк белем ярышларында да уңышлар телибез.

***Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Илдар Сафиуллин***

## *Яңа елны каршылап*

***/Безнең бәйрәмнәр/***



26 декабрь көнне безнең мәктәптә Яңа ел тамашасы уздырылды. Бәйрәм чыршы бизәүдән башланды. Укучылар бик актив әзерләнде. Иң беренче булып бәйрәмне 1-5 сыйныф укучылары башлап җибәрде. Алар безгә бик матур чыгыш ясадылар. Чыгышлар арасында төрле конкурслар да оештырылды. Укучылар конкурсларда бик актив катнаштылар. Балаларны яңа ел белән котларга Кар кызы белән Кыш бабай килде. Ул капчыгында Яңа ел символын "Үгезне" алып керде. Алар укучылар белән чыршы тирәли биеделәр, уйнадылар. Башлангыч сыйный кызлары "Кар бөртекләре" биюен, ә 5-нче сыйныф укучысы Нургалиева Ләйлә керәшен биюен башкарды. 5-нче сыйныфларның курчак театры да бик кызыклы килеп чыкты. Яңа ел бәйрәмендә йолдыз булып Убырлы карчык килгән иде. Аның ролен, безнең мәктәп пешекчесе Илсөяр апа башкарды. Пешекче апабызны тәмле пешерүче иттереп кенә белә идек, ул сәхнәдә дә үзен сынатмый икән. Бәйрәмне бик оста итеп башлангыч сыйныфлар укытучысы Гафиятуллина Зөлфия апа алып барды. Ахырдан бәйрәмгә маскарад киемнәре әзерләгән, рәсемнәр һәм төрле эшләнмәләр ясаган укучыларга бүләкләр бирелде.

---



Бәйрәм түрен кич белән зур сыйныфлар биләде. Алар 3 төркемгә бүленеп ярыштылар: "Гринчлар", "Мандариннар" һәм "Йолдызлар" командалары. Бәйрәм командаларның таныштырулары белән башланып китте. Аннан соң төрле конкурслар, мода күрсәтү, скетчлар башкарылды. Күзне бәйләп рәсем ясау, бию, табышмаклар, мәкальләр әйтешү ярышлары уздырылды. Укучылар барлык конкурсларда да бик актив катнаштылар. Жюри исәпләве буенча беренче урынны "Гринчлар" командасы яулады, икенче урын "Йолдызлар" командасына бирелде, өченче урынны "Мандариннар" алды. Кичке тамашаны Гафиятуллина Руфия апа алып барды. Катнашучылар да, тамашачылар да бәйрәмнән бик канәгать калдылар.

---

Балалар бакчасы тамашасы ел саен үзенчәлекле итеп үткәрелә. Быел ул 28-нче декабрь көнне уздырылды. Балаларны бәйрәмгә Насыйрова Гөлүсә һәм Нәҗметдинова Ләйсән апалар әзерләде. Нәниләрне сәхнәдә күрүгә үк күңелләр шатланып, алар өчен сөенеп куясың. Аларны Кыш Бабай төрле уеннарда катнаштырды. Сәхнәдә җырлар, биюләр дә башкарылды. Сабыйларның һәрберсе Яңа елны каршыларга бәйрәмчә маскарад киемнәре киеп килгән иде. Тамашадан соң балаларга район башлыгы Гилманов Камил Камал улы исеменнән яңа ел бүләкләре өләшенде. Шундый ук бүләкләр I-IX сыйныф укучыларына да бирелгән иде.

***Бәйрәм тамашаларыннан репортажны IX сыйныф укучылары***
***Әминә Туктамышева, Зөлфирә Сафиуллина, Вика Нукина әзерләде***

## Әби-бабаларыбыз математиканы ничек өйрәнгән?

Кеше тормышын исәп-хисап алып барудан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Шул сәбәпле, математик белемнәр кешеләр өчен бик борынгы заманнарда ук кирәк булган. Һәр халыкның телендә саннарны белдерү өчен аерым сүзләр куллану моңа дәлил булып тора. Математик белемнәрне махсус укыту мәгариф эшчәнлеге башланган дәверләрдән үк килә.

Безнең татар халкының борынгы бабаларында мәгариф системасы Ислам динен кабул итү белән калыплаша башлый. Урта гасырларда мөселман илләрендә төрле фәннәргә, шул исәптән математикага да, игътибар бик зур була. Алгебра, тригонометрия кебек фәннәрнең барлыкка килүе, саннарны аерым тамгалар белән билгеләү, нульне гамәлгә кертү мөселман математикларының эшчәнлегенә бәйле. Мөхәммәт әл-Хәрәзми, Әхмәт ән-Нәсәви, Шәрәфетдин әт-Туси, Гыясетдин әл-Кашани кебек математикларның хезмәтләре бөтен дөньяга мәгълүм. Борынгы болгар-татар дәүләтләре чорында мәдрәсәләрдә нинди фәннәр укытылуы төгәл билгеле түгел. Укыту эше яңадан җанланып киткән XVIII гасырда, арифметика һәм геометрия фәннәре дини һәм тел белемнәре белән беррәттән укытылган. Бу хакта Казан мәдрәсәләре турында язган 1811 елгы “Вестник Европы” газетасы хәбәр итә. 1844 елгы документ буенча арифметика кагыйдәләре Казандагы 8 мәдрәсәнең барысында да укытылган. Әлеге мәдрәсәләр иске ысул белән укыткан, дини белемнәргә өстенлек биргән кадими уку йортларыннан саналганнар. XIX гасыр ахырында укыту ысулы һәм программалары заман таләпләренә яраклаштырылган җәдит мәдрәсәләре барлыкка килә. Җәдиди уку йортларында дөньяви фәннәр, шул исәптән, математикага да игътибар тагын да арта.



Моннан 7-8 еллар элек, авылыбызда революциягә кадәр эшләп килгән мәдрәсәдә хисап (математика) фәне буенча бирелгән белем дәрәҗәсен ачыклау максатыннан, мәктәп музеенда саклана торган дәреслекләрне анализлаган идек. Тикшеренү үзебездә табылган 6 математика дәреслеге буенча үткәрелгде. Шуларның дүртесе тулысынча диярлек сакланган, икесе – берничә битлек фрагмент хәлендә. Китапларның авторлары, басылу вакытлары, терминнары һәм эчтәлекләре дә төрле. Дүрт китап – дәреслектән, икесе – мәсьәләләр җыентыгыннан гыйбарәт. Тикшеренү предметына әлеге китапларның бишесе – революциягә кадәр басылып чыкканнары туры килә. Совет чорында басылган бер китап башкалары белән чагыштыру максатыннан җәлеп ителде. Гәзитнең алдагы саннарында без аларның һәрберсе буенча аерым материал бирергә тырышырбыз. Шуның өстенә, элек тикшерелгән китаплардан тыш музей тупланмасында тагын ике хисап дәреслеге пәйда булды.

Инкыйлабка кадәр авылыбыз мәдрәсәсендә укытылган математика дәреслекләрен тикшерү түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә:

- дәреслекләр барысы да арифметиканың дүрт гамәлен өйрәтүгә нигезләнгән;
- укытуның башында натураль саннар, ахырда вакланмалар белән эш итү каралган;
- чишелергә тиешле мәсьәлә биремнәре алган белемнәрнең көндәлек тормышта кулланылуын күздә тотып төзелгән;
- биремнәрдә төрле үлчәү берәмлекләре белән эш итүгә зур игътибар бирелә;
- кадими укыту ысулыннан җәдидигә күчү барышында элек гамәлдә булган гарәпчә математик терминнар халыкка күбрәк аңлаешлы татарча төшенчәләр белән алыштырылган;
- тикшерелгән китапларда тискәре саннар белән исәпләү, тигезләмәләр чишү буенча биремнәр юк, шулай ук алгебра белән геометрияне өйрәнү дә каралмаган.

Бу тикшеренү бары тик бер авылда сакланып калган китаплар буенча гына үткәрелде. Шул сәбәпле, югарыда чыгарылган нәтиҗәләр патша чоры татар мәгарифе өчен тулаем хас күренеш дип әйтә алмыйбыз. Йомгаклап әйткәндә, татар милли мәгарифенең мәдрәсә чорында укучыларга математика фәнен өйрәтүгә тиешле игътибар бирелгән. Җәдиди уку йортларында гына түгел, кадимиләрдә дә математика укыту өчен тоткарлыклар булмаган. Әлбәттә, һәр мәктәп һәм мәдрәсәдә бу эш тиешле югарылыкта торган дип әйтеп булмый. Чөнки ул заманда белем бирүнең сыйфатын арттыруга китерерлек мәҗбүри укыту программалары буенча эшләү, мөгаллимнәрне аттестацияләү, дәреслекләр белән тәэмин итү кебек чаралар күрелмәгән. Шуңа да карамастан, әби-бабаларыбыз математикадан заманына күрә җитәрлек күләмдә белемгә ия булганнар дип әйтә алабыз.

*Тарих фәннәре кандидаты Рафик Насыйров*

## Фаилнең уңышлары

**/Безнең спорт/**




Шахмат уены ми күзәнәкләренең эшчәнлеген арттыра, кешедә ихтыяр көче булдыруга булышлык итә, вакытны телефон, компьютер уйнау кебек кирәксез эшләргә сарыф итүдән саклый икәнен без яхшы беләбез. Күп кенә район, шәһәрләрнең дә әлеге уен төре белән нык кызыксынуы, төрле өлкәләрдән зур шахматчылар тәрбияләнүе дә барыбызга да мәгълүм. Шундый урыннарның берсе – ул Баулы шәһәре. Инде менә 38 ел рәттән декабрь аенда анда **Р.Г.Нәҗметдинов истәлегенә багышланган традицион, региональ шахмат турниры** үткәрелә. Әлеге турнир региональ булганлыктан, анда Татарстан Республикасыннан тыш башка регионнар да катнашырга хокуклы. Быел үткән бу зур дәрәҗәле турнирда Чистай шәһәре командасы составында, мәктәбебез шахматчысы Гафиятуллин Фаил дә катнашты. Уен 13-нче декабрьдә башланып, 3 көн дәвам итте. Монда Татарстан, Оренбург өлкәсе, Самара командалары көч сынашты. Уен бик кызу үтте. Командалар көчле, барлык спортчының да теләге бер – җиңү. Алган очколар команда исәбенә дә, шәхси исәпкә дә язылды. Турнир нәтиҗәләре буенча, 2009-нчы елгы һәм алардан кечерәк шахматчылар арасында **Гафиятуллин Фаил** 1-нче урынга, шулай ук, ул кергән Чистай шәһәре командасы да 1-нче урынга лаек булды. Җиңүчеләр алтын медальләр, грамоталар, акчалата бүләкләр белән бүләкләнделәр. Шахматчыларга, аларның тренеры Илнур Рафик улы Шәмсетдиновка, йөртүче Фәнил Фаик улы Гафиятуллинга рәхмәт әйтеп, киләчәктә уңышлар телисе килә.

Узган айда Фаил Аксубай районының яшьләр һәм спорт эшләре буенча комитеты тарафыннан уздырылган Татарстанның атказанган физкультура хезмәткәре В.А.Горбунов истәлегенә яшьләр арасында үткәрелгән региональ онлайн-турнирда, һәм Ю.В.Сухалов кубогына үткәрелгән район онлайн-турнирында катнашып, һәр икесендә дә 2-нче урынга лаек булды.

Кышкы каникулның беренче көннәрендә (26.12- 30.12.2020) Чистай шәһәрендә 2008-2009 елгы кызлар һәм малайлар арасында шәһәр беренчелегенә классик шахмат төре буенча турнир уздырылды. Турнирда мәктәбебезнең ике шахматчысы **Фаил Гафиятуллин** һәм **Айназ Хәйруллин** катнашты. Катнашучылар көн саен дүртәр сәгать шахмат тактасы артында булдылар. Турнир нәтиҗәләре буенча Фаил 2-нче урынны яулады.

***Руфия Гафиятуллина, VII сыйныф җитәкчесе***

## Көрәштә җиңүчеләр арта



Пандемия сәбәпле, узган елның мартыннан бирле төрле массакүләм спорт чаралары тукталып килгән иде. Шулай да, рөхсәт бирелү белән, уку елы башыннан мәктәптәге көрәш түгәрәге үзенең эшен яңадан башлап җибәрде. Түгәрәккә йөрүчеләр саны артканлыктан, тренерлары **Илһам Камалов** көрәшчеләрне ике төркемгә бүлеп шөгыльләндерә башлады. Инде менә бу айда яңа сезонның беренче ярышлары да булып узды. 12-нче декабрьдә Норлат шәһәрендә үткәрелгән көрәштә **Җамалетдинов Зөлфәт**, **Галимов Рияз** һәм **Нурматов Халит** үз авырлыкларында III урыннарны, **Хәбибрахманов Ильяс** II урынны яулап кайттылар. Әле быел гына көрәшкә йөри башлаган II сыйныф укучысы Җамалетдинов Зөлфәт зур келәмдә үзен күрсәтә алуы аеруча шатландырды

Көрәшче егетләребезнең чираттагы җиңүләре 23-нче декабрьдә “Чулпан авылы көрәш мәктәбе” призына уздырылган Норлат районы билбау көрәше беренчелегендә булды. **Камалов Илдус** 55 кг авырлыкта I урынны алды. Афәрин, егетләр!!!

**/Котлыйбыз!/**



Декабрь аенда дөньяга килгән балалардан, бакча төркеменнән **Гафиятуллина Руфинәне** (??.12.????), VIII сыйныф укучысы **Әхсәнов Халитны** (??.12.????) туган көннәре белән котлыйбыз. Укуларында уңышлар, сәламәтлек телибез.

Хезмәт юлын мәктәбебездә рус теле һәм әдәбиятын укытуга багышлаган **Рушания апа Нәҗметдинованы** гомер бәйрәме белән котлыйбыз. Хөрмәтле Рушания апа! Барлык изге теләкләребез кабул булсын. Сезгә ныклы сәламәтлек, күңел күтәренкелеге, гаилә бәхете теләп калабыз!

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Сара Насыйрова
Виктория Нукина
Рузилә Мөхәмматова
Зөлфирә Сафиуллина